**Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы**
**Ошторма Юмья авыл җирлеге башлыгы**
**КАРАРЫ**

**05 ноябрь 2020 ел** **№8**

**«Кукмара муниципаль районы Ошторма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылы торак пунктында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыены үткәрүне билгеләү турында»**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы һәм Кукмара муниципаль районы Ошторма Юмья авыл җирлеге Уставының 22 статьясы нигезендә карар бирәм:

1. 2020 елның 20 ноябренә 15 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ошторма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының беренче этабын үткәрүне билгеләргә.

2. 2020 елның 20 ноябренә 17 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ошторма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының икенче этабын үткәрүне билгеләргә.

3. 2020 елның 20 ноябренә 19 сәгать 00 минутка Кукмара муниципаль районы Ошторма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылында үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыенының өченче этабын үткәрүне билгеләргә.

4. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга: «Көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлар, гомуми белем бирү мәктәпләрендә укучылар, I төркем инвалидлары, 80 яшьтәге һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге пенсионерлардан туендыручысын югалткан күп балалы гаиләләрдән тыш кала, Татарстан Республикасы Кукмара муниципаль районы Ошторма Юмья авыл җирлегенең Иске Юмья авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр яшәүчедән 2021 елда үзара салымны 500 сум күләмендә кертергә һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен юнәлтүгә сез ризамы:

- Яр буе, Гвардия урамы, Үзәк урамы, Мәктәп урамы, Иске Юмья авылы юлларын ремонтлау (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, таш сатып алу, ташу, җәю, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- Иске Юмья авылында янгын гидрантларын сатып алу һәм урнаштыру (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, янгын җиңелләре, стволлар, күчеш һәм колонкалары сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);
- чишмәләрне һәм су белән тәэмин итү системаларын төзекләндерү (ремонтлау) (разработка проектно-сметной документации и осуществление технадзора, приобретение материала, оплата работ по договору);
- Иске Юмья авылы зиратына койма кую (проект-смета документациясен эшләү һәм техник күзәтчелекне гамәлгә ашыру, материал сатып алу, килешү буенча эшләр өчен түләү);

- видеокамера сатып алу һәм урнаштыру (килешү буенча эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү);

- Иске Юмья авылының урам юл челтәрен карап тоту (юлларны кардан һәм территорияне җәйге чорда чабу; ягулык-майлау материаллары, запас частьләр сатып алу, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү)?”

«РИЗА» «КАРШЫ»

5. Иске Юмья авылы, Үзәк урамы, 87а йорт адресы буенча урнашкан Иске йомма авыл мәдәният йорты бинасында халык җыены этапларын үткәрү.

6. Халык җыенын үткәрү өчен торак пунктта яшәүчеләрнең исемлеген территориаль билге буенча (урамнар буенча) хәл итәргә.

7. Гражданнар җыенын оештыручы итеп, Ошторма Юмья авылы Башкарма комитетын билгеләргә.

8. Әлеге карарны кабул ителгән көннән соң 5 көн эчендә мәгълүмат стендларында һәм Кукмара муниципаль районының рәсми сайтында «Авыл җирлекләре» бүлегендә урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

9. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Ошторма Юмья авыл җирлеге башлыгы: С.Г. Антонов